ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы муниципаль районынын**
**Сөйки авыл жирлеге Башкарма комитеты**

Кама Тамагы районы,
Сөйки авылы
тел. 8 (843) 77 36-3-38
РТ Камско-Устьинский район
с. Сюкеево ул. Колхозная дом 16а

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**Исполнительный комитет Сюкеевского сельского поселения**

Камско-Устьинский район,
с. Сюкеево
тел. 8 (843) 77 36-3-38
РТ Камско-Устьинский район с. Сюкеево ул. Колхозная дом 16а

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**2022 елның 6 декабре** **№16**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге территориясендә , эштән чыккан терекөмешле лампаларны беренчел җыю урынын билгеләү һәм туплау турында**

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар,"Гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган электр лампаларын тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызлау, ташу һәм урнаштыру өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында "2004елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән , Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында Татарстан Республикасы Законы,"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, терекөмешле лампалар белән эш иткәндә халыкның экологик һәм санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү максатларында,Татарстан Республикасы Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге территориясендә,эштән чыккан терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм туплау урынын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Сөйки авылы, Казан урамы,
49 й.

2. Түбәндәге график буенча эштән чыккан терекөмешле лампалар җыюны оештырырга:

- Һәр пәнҗешәмбе 08.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» (https://kamskoye-ustye.tatarstan.ru/) мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **П.В. Сорокин**